РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«7» май 2025г. г. Альметьевск №173

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының
2018 елның 11 маендагы 113 номерлы
«Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре
муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә
түләү тәртибе һәм шартлары турында»
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең Контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы карары нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2018 елның 11 маендагы 113 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2020 елның 30 октябрендәге 8 номерлы, 2021 елның 16 декабрендәге 58 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 67 номерлы, 2022 елның 5 октябрендәге 82 номерлы, 2022 елның 28 декабрендәге 92 номерлы, 2024 елның 26 июнендәге 145 номерлы, 2024 елның 26 декабрендәге 161 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибенең һәм шартлырның 2 пункты 5 пунктчасында «41 процент» сүзләрен «58 процент»сүзләренә алмаштырырга.;

1.2. карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре
муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре

(сумнарда)

| «Вазыйфа исеме | Вазыйфаи оклад |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 42 166 |
| Идарә җитәкчесе мөстәкыйль бүлек җитәкчесе (мөдире), Башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе | 29 240 |
| Идарә  җитәкчесеурынбасары, мөстәкыйль бүлек җитәкчесе (мөдире) урынбасары, Башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары | 24 469 |
| Башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе, Башкарма комитет җитәкчесе киңәшчесе | 24 469 |
| Башкарма комитет идарәсе составындагы бүлек башлыгы | 24 469 |
| Сектор мөдире | 22 930 |
| Баш белгеч | 22 468 |
| Әйдәп баручы белгеч | 21 083 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 19 545» |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле елга җирле бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә (Шәйхетдинова Ф.А.) йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы

«АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ»

И.Р. Баһманов